РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ЧИСТОПОЛЬСКИЙ ГОРОДСКОЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЧИСТАЙ ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**Постановление** *Карар*

**06.10.2025** **Чистай шәһәре** **№ 202**

Чистай шәһәр Башкарма комитетының
2021 елның 28 июнендәге 92 номерлы
карары белән расланган даими рәвештә
пассажирлар йөртү һәм багаж ташу
маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм
багаж ташуны гамәлгә ашыру турында
таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар
йөртү һәм багаж ташу маршруты карталарын
рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт
күрсәтүнең административ регламентына
үзгәрешләр кертү хакында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Чистай шәһәр Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Чистай шәһәр Башкарма комитетының 2021 елның 28 июнендәге 92 номерлы карары белән расланган даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклыкны һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты карталарын рәсмиләштерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең административ регламентының 2 өлешендәге 2.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru/) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Чистай шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты
җитәкчесе И.Ф. Рәхимов